ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

04 декабрь 2024 ел № 8114

Башкарма комитетның 2022 елның 23 ноябрендәге 6572 номерлы Карары белән расланган «Балаларны мәктәпкәчә белем бирү программаларын тормышка ашыра торган муниципаль белем бирү оешмаларына исәпкә кую һәм җибәрү» муниципаль хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Хәрби хезмәткәрләр статусы турында» Федераль законның 19 һәм 24 статьяларына һәм «Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләре турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 24 июнендәге 281-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 42 статьясы нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2022 елның 23 ноябрендәге 6572 номерлы Карары белән расланган «Балаларны мәктәпкәчә белем бирү программаларын тормышка ашыра торган муниципаль белем бирү оешмаларына исәпкә кую һәм җибәрү» муниципаль хезмәте күрсәтүнең административ регламентына, 1.3 пунктны һәм 1.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«1.3. Мәктәпкәчә төп белем бирү программасын тормышка ашыра торган белем бирү оешмаларына (алга таба – Оешма) чираттан тыш урнашу хокукына ия:

судьяларның балалары;

прокурорларның һәм Россия Федерациясе Тикшерү комитеты хезмәткәрләренең балалары;

Чернобыль АЭСындагы һәлакәт нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар ителгән гражданнарның һәм аларга тиңләштерелгән категориядәге гражданнарның балалары;